КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.08.2024 № 420-П

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2022 елның 10 нчы ноябрендә гамәлгә кергән «Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш) мәгълүмати язмалар һәм аңлатмалар проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 425-П номерлы боерыкка үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2022 елның 10 нчы ноябрендә гамәлгә кергән «Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш) мәгълүмати язмалар һәм аңлатмалар проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы боерыкка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында»гы, 2010 нчы елның 27 нче июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 нче елның 28 нче февралендә гамәлгә кергән «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында»гы карары нигезендә боерык бирәм:»;

күрсәтелгән боерык белән расланган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмати язмалары һәм аңлатма проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының кушымтасы (белешмәсе) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Хокук, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эшләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвен узу өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин